ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09 июнь 2023 ел № 4938

Яр Чаллы шәһәренең социаль-икътисадый үсеш фаразын эшләү тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 173 статьясы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) дәрәҗәсендә социаль-икътисадый үсешне стратегик планлаштыруны гамәлгә ашыру буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2015 елның 18 декабрендәге 534 номерлы боерыгы, шәһәр Уставының 53, 75 статьялары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең социаль-икътисадый үсеш фаразын эшләү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитет карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Яр Чаллы шәһәренең социаль-икътисадый үсеш фаразы проектын формалаштыруны оештыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 1 декабрендәге 4691 номерлы;

2) «Яр Чаллы шәһәренең социаль-икътисадый үсеш фаразы проектын формалаштыруны оештыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 26 апрелендәге 2125 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 9 июнендәге
4938 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
социаль-икътисадый үсеш фаразын эшләү
тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип, Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразын (алга таба – фараз) үз вакытында һәм сыйфатлы эшләү максатында эшләнгән.

2. Фараз – фаразлана торган чорга юнәлешләрне һәм көтелгән нәтиҗәләрне үз эченә алган стратегик планлаштыру документы. Фараз ел саен киммендә өч еллык чорга әзерләнә.

3. Фараз, бер үк вакытта Шәһәр Советына шәһәр бюджеты проектын кертү турында карар кабул итеп, Башкарма комитет тарафыннан хуплана. Шәһәр бюджеты проектын төзү яки карап тикшерү барышында фаразны үзгәртү шәһәр бюджеты проектының төп характеристикаларын үзгәртүгә китерә.

4. Фараз төзү өчен төп база булып түбәндәгеләр тора:

- Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль собраниесенә юлламасы;

- Россия Федерациясе социаль-икътисадый үсешенең сценар шартлары, агымдагы һәм план чорына Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеш фаразының төп параметрлары;

- Федераль дәүләт статистикасы хезмәте территориаль органы, Федераль салым хезмәте инспекциясе, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды, «Яр Чаллы шәһәренең халкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ мәгълүматы;

- фаразлауда катнашучылар тарафыннан тәкъдим ителгән материаллар һәм эксперт бәяләре.

2 бүлек. Фаразны эшләүнең төп нигезләмәләре

5. Фараз соңгы хисап чорында Яр Чаллы шәһәренең социаль-икътисадый үсеш мәгълүматлары, планлаштырыла торган чорга икътисад һәм социаль өлкә үсеше тенденцияләре нигезендә эшләнә.

6. Фаразны эшләү һәм формалаштыру Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7. Фаразлау процессында катнашучылар булып, билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә, фаразны эшләү өчен мәгълүмат әзерләүне гамәлгә ашыручы яки эшчәнлек төрләре буенча аның аерым параметрларын исәпләүче Башкарма комитет структур бүлекчәләре тора.

8. Фараз Татарстан Республикасының фараз күрсәткечләре системасы аша белдерелгән Яр Чаллы шәһәре үсешенең сан һәм сыйфат характеристикаларын үз эченә ала.

9. Фараз Яр Чаллы шәһәренең социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләренең хисап һәм фаразлана торган зурлыклары булган таблицадан һәм аңа аңлатма язуыннан гыйбарәт.

10. Таблица икътисадның һәм социаль өлкәнең төп юнәлешләре буенча бүлекләргә берләштерелгән күрсәткечләр системасын үз эченә ала. Фаразлана торган чорның бәя күрсәткечләре индекс-дефляторларны исәпкә алып исәпләнә.

11. Фаразга аңлатма язуында түбәндәгеләр булырга тиеш:

- агымдагы елда шәһәрнең социаль-икътисадый үсешенең ирешелгән дәрәҗәсен бәяләү;

- шәһәрнең социаль-икътисадый үсешенең тышкы һәм эчке шартларын, факторларын һәм чикләүләрен бәяләү;

- шәһәрнең социаль-икътисадый үсешенең төп юнәлешләре һәм күрсәткечләре.

12. Фаразны эшләү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы үсешенең сценар шартларында бәян ителгән факторларның йогынтысын исәпкә алып һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары белән расланган срокларда (Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразын эшләү графигы), бер вариантта гамәлгә ашырыла.

13. Фаразны эшләү бердәм методология нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан эшләнгән методик тәкъдимнәргә туры китереп гамәлгә ашырыла.

14. Фаразны эшләү функцияләрен үтәү өчен Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе:

- чираттагы елга һәм финанс чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын эшләү турында Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына, муниципаль хокукый актларга таянып, фараз эшләүне оештыра;

- фаразлау процессында катнашучыларны билгели;

- Яр Чаллы шәһәре социаль-икътисадый үсешенең фараз күрсәткечләрен исәпләү һәм мониторинглау буенча фаразлау процессында катнашучыларның эшчәнлегенә методик җитәкчелекне һәм координацияләүне гамәлгә ашыра;

- килеп туган хәлне һәм шәһәр үсеше тенденцияләрен анализлау нигезендә, Башкарма комитетның тармак структур бүлекчәләре тарафыннан тәкъдим ителгән материалларны исәпкә алып, фаразны эшли;

- эшләнгән фараз күрсәткечләрен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрә һәм аның тарафыннан билгеләнгән срокларда килештерә;

- кирәк булганда, Икътисад министрлыгы белән килешү нәтиҗәләре буенча һәм социаль-икътисадый үсеш фаразын аныклау турында методик материаллар алганда, фараз күрсәткечләренә төзәтмәләр һәм үзгәрешләр кертүне гамәлгә ашыра;

- Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан билгеләнгән срокларда «Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше» автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик системасына (алга таба – ТРСИҮ МАС) килештерелгән фараз күрсәткечләрен кертә;

- фаразны хуплау турында Башкарма комитет карары проектын әзерли;

- хупланган фаразны «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыра.

## 3 бүлек. Фараз турында иҗтимагый фикер алышу

15. Фараз проекты буенча иҗтимагый фикер алышу (алга таба – иҗтимагый фикер алышу) процедурасын үткәрү икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе тарафыннан тәэмин итәлә һәм, түбәндәге мәгълүматны күрсәтеп, фараз проектын Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла:

1) фараз проекты буенча иҗтимагый фикер алышуны башлау һәм тәмамлау срогы;

2) шәһәр Башкарма комитетының юридик адресы һәм электрон почта адресы, фараз проекты буенча кимчелекләр һәм тәкъдимнәр җибәрү өчен элемтә телефоны;

3) фараз проекты буенча тәкъдимнәр һәм кимчелекләр җибәрү тәртибе.

16. Фараз проектын «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру белән бер үк вакытта, фараз проекты буенча иҗтимагый фикер алышуны башлау турында хәбәр бастырып чыгарыла.

17. Иҗтимагый фикер алышу, фараз проекты рәсми сайтта урнаштырылган көннән башлап, 7 календарь көн дәвамында үткәрелә.

18. Фараз проектына тәкъдимнәр һәм кимчелекләр тәкъдим итү характерында.

19. Фараз проекты буенча иҗтимагый фикер алышу срогы тәмамланганнан соң, икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе кергән тәкъдимнәр һәм кимчелекләр нигезендә, 10 көн срокта фараз проектын эшләп бетерә.

20. Фараз проекты буенча иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре буенча кергән тәкъдимнәрне һәм кимчелекләрне кабул итү (кире кагу) турында карар Башкарма комитет беркетмәсе (алга таба – Беркетмә) белән раслана һәм, иҗтимагый фикер алышу срогы тәмамланганнан соң 20 көннән дә соңга калмыйча, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырыла.

4 бүлек. Социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләрен мониторинглау

21. Фараз күрсәткечләрен мониторинглау һәм контрольдә тоту, күрсәткечләрнең факттагы зурлыклары фаразда хупланган зурлыклардан тайпылышын ачыклау максатында, рәсми статистик мәгълүмат, шулай ук фараз эшләүдә катнашучылар тарафыннан бирелгән мәгълүмат нигезендә, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева